**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**15 июнь 2023 ел** **№ 105**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында 2022 елның 22 сентябрендәге 81 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан транспорт прокуратурасының 2023 елның 21 февралендәге 23/1-12-23 номерлы протестына бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 3 өлеше нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Федераль законның 23 статьясына таянып, Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында 2022 елның 22 сентябрендәге 81 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 41 статьяның 5 пунктчасында 10 бүлектә «һәм тимер юлның» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 14 бүлекнең 54 статьясының 3 пунктының 1 пунктчасында «тимер юл» сүзен төшереп калдырырга;

3) 15 бүлекнең 59 статьясының 1 һәм 4 пунктларында «тимер юл» сүзен төшереп калдырырга;

4) 15 бүлекнең 60 статьясының 1 пунктында «тимер юл» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев